# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ

## КАРАР №17

III чакырылыш чираттан тыш утырышы     Урыссу штб «9» август 2019 ел

*Ютазы муниципаль районында муниципаль*

*хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү*

*хакында*

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2018 елның 13 декабрендәге 41 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Ютазы район Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2018 елның 13 декабрендәге 41 номерлы карары белән расланган Ютазы район Советының муниципаль хезмәт турында Нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 6 бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 6.4 пунктчасы белән тулыландырырга:

«6.4. Җитәкче булып торган муниципаль хезмәткәр, Ютазы муниципаль районының җирле үзидарә органында мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау максатларында, әлеге вазыйфаны биләгән чорда әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклый алмый».

2. 7 бүлекнең 1 өлеше 2 пункты 7.1. пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яисә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (сәяси партия белән идарәдә катнашудан тыш; профсоюз органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашудан тыш; съездда (конференцияләрдә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж коперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтләренең гомуми

җыелышында катнашудан тыш); әлеге коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән һәм һөнәри берлек органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән башлангыч һөнәр берлегенең сайланулы органыннан тыш) белән, яллаучы (эш бирүче) вәкиле рөхсәте белән, бер генә башкарма орган буларак яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүдә түләүсез нигездә катнашырга, муниципаль хокукый актлар нигезендә, муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү вәкаләтләрен гамәлгә кую тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә, гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) оешма һәм ревизия комиссиясе мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тапшырудан тыш;  федераль законнарда каралган башка очраклардан тыш;».

3. Әлеге карар аңа кул куелганнан соң үз көченә керә.

*Ютазы муниципаль районы Башлыгы –*

*Ютазы район Советы Рәисе* *Р.М. Нуриев*